**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **28.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Балтач авыл җирлегенэ
керүче Балтач авылында 2020 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегендә халык җыены карар бирэ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (дурт йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Балтач авылы, Яшьләр урамы, Үзәк урамы, А. Алиш урамы ,8март урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу,ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү); ;
- Балтач авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;;

Балтач авылында күперне ремонтлау ;

Балтач авыл мәдәният йорты өчен генератор сатып алу;

- Балтачта «Җиңү көне», «Сабантуй» ,«өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;;

Балтачта юлларны кардан чистарту;

- Балтач авылы территориясендә чүп үләнен чабу;

Балтач авылы зираты территориясендә чүп үләннәрен чабу

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы, Яшьлэр ур., 1А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Балтач авыл җирлеге башлыгы: Хэбипов Л.Л.